СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.01.2023 г. Заинск № 271

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 87-89 статьялары нигезендә, Зәй муниципаль районының гамәлдәге Уставы нигезләмәләрен законнарга туры китерү максатында, Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Советының 2014 елның 24 июнендәге 385 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Зәй муниципаль районы Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәве өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына кертелгән үзгәрешләрне, билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве узганнан соң, мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.
4. Карар дәүләт теркәве узганнан һәм билгеләнгән тәртиптә бастырылганнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Советының законлылык, регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе Р.Г. Кәримов

Зәй муниципаль районы Советының
2023 елның « 27 » 01
271 номерлы карарына кушымта.

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына үзгәрешләр**

Зәй муниципаль районы Уставына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләрне кертергә:

1. 6 статьяда:

а) 1 өлешнең 36 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«36) федераль закон нигезендә муниципаль район ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрнең үтәлешен тәэмин итү;»;

б) 3 өлешнең 23 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23) федераль закон нигезендә муниципаль район ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрнең үтәлешен тәэмин итү;»;

2. 19 статьяда:

а) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Үткәрү вакытын һәм урынын күрсәтеп, ачык тыңлаулар үткәрү турында мәгълүмат, шулай ук ачык тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, ачык тыңлаулар үткәрелә торган көнгә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча, район территориясендә таратыла торган матбугат чараларында бастырылырга, шул исәптән районның рәсми сайтында, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш»;

б) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Ачык тыңлаулар үткәрү һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты турында мәгълүмат басылып чыккан көннән район халкы ачык тыңлауларга чыгарылган мәсьәлә яки муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне район башлыгына җибәрергә хокуклы, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша да.».

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җибәрү гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча туктатыла.

Район башлыгы кергән тәкъдимнәрне гомумиләштерүне һәм аларны ачык тыңлауларда катнашучыларга җиткерүне оештыра.»;

в) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре район территориясендә таратыла торган массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән районның рәсми сайтында һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында ачык тыңлаулар уздырылганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.»;

3. 45 статьяда:

а) 1 өлешнең 3 пункты 9 абзацында «, ясалма җир участогы булдыру турында килешү төзү хокукына ачык аукцион үткәрә» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

« - муниципаль янгын сагын булдыра.»;

4. 45.1 статьяның 25 абзацында «, ясалма җир участогы булдыру турында килешү төзү хокукына ачык аукцион үткәрә» сүзләрен төшереп калдырырга;